ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2021 ел № 6/7

Шәһәр Советының «Авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен муниципаль милеккә аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында» 2019 елның 1 августындагы 32/8 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 13-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль закон»га һәм «Ярдәм алучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрын формалаштыру максатларында Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен муниципаль милеккә аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында» 2019 елның 1 августындагы 32/8 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) исемдә «һәм эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләре, муниципаль программаларда (ярдәмче программаларда) билгеләнгән башка өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен өстәргә;

2) 1 пунктның 1 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар өчен муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукыннан ирекле булган (хуҗалык алып бару, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларның мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт өчен аренда түләве буенча ташламаларны түбәндәгечә билгеләргә:

3) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Арендатор тарафыннан аренда килешүе буенча йөкләмәләрнең үтәлмәве сәбәпле, яки арендатор әлеге Карарның 1 пунктында каралган критерийларга туры килми башлаган очракта, авыл хуҗалыгы кооперативлары яки социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, социаль әһәмиятле эшчәнлек, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар белән муниципаль мөлкәтне арендалау килешүен вакытыннан алда өзгәндә, муниципаль милектән фактта файдалану вакыты арендалау килешүендә билгеләнгән аренда бәясеннән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

